ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» апреля 2020 ел № 117

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең дежур төркемен «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 8 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә күчерү турында

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә капиталь ремонт үткәрелү, якын территорияне төзекләндерү сәбәпле һәм Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2013 елның 15 маендагы 26 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын төзүгә, карап тотуга һәм эш режимын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» (СанПиН 2.4.1.3049-13) санитар-эпидемиологик кагыйдәләре һәм нормативларының 17.11 пункты нигезендә, «2020 елда биналары капиталь ремонтланырга тиешле гомуми белем бирү оешмалары исемлеген Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән раслау турында» 05.03.2020 елгы 481-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 мартындагы 98 номерлы карары нигезендә, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең дежур төркемен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 8 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә 2020 елның 13 апреленнән 2020 елның 30 апреленә кадәр күчерергә.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 6 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү

учреждениесе мөдиренә, МКУ «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» башлыгына:

- балигъ булмаганнарның хокукларын яклауга һәм гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрергә;

- әлеге Карарны гамәлгә ашыру буенча локаль норматив актлар кабул итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**